**Нырты авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**04 июль 2023 ел** **№12**

**Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турындаНырты т. п. гражданнар җыенының 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Нырты авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Нырты авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елның 14 июленә 08 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 14 июленә 12 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

3. 2023 елның 14 июленә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

4. 2023 елның 14 июленә 20 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Нырты авылы, Мәктәп урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәктәп бинасында үткәрергә.

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Нырты т. п. гражданнар җыенының 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 6 абзац 2 пунктта «урам якыртуын тээмин итү» сүзләрен «су системасын тээмин итү» сүзләренә алмаштырырга»;

- 2 пунктка киләсе эчтәлеккә яңа абзац өстәргә «Вак таш сатып алу (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү)»

«РИЗА» «КАРШЫ»?».

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Нырты авыл җирлеге
башлыгы: Т.А. Котдусов

ОГРН 1021607754563
ИНН 1623001710